**Совет Поповского сельского поселения**
**Заинского муниципального района Республики Татарстан**

# РЕШЕНИЕ

**№88** **29.05.2023 г.**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлегендә җәмәгать тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 21 мартында 151 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертү турында**

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 21 мартында 151 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлегендә җәмәгать тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) үткәрү тәртибе турында нигезләмәнең 12 статьясы 5 өлешенә, «бер ай һәм өч айдан артык» сүзләрен «ундүрт көн һәм утыз көннән артык» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлек торак пунктлары

территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет рәисе И.Э.Эмерханов